**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 3 октябрь № 738

г. Казань

2016 елга дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен (карарга теркәләләр) расларга.

2. Социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләрнең бу карарның 1 нче пункты белән расланган күләмнәре барлык милек рәвешендәге һәм теләсә кайсы ведомствога караган белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары, урта звено белгечләрен әзерләү программалары, бакалавриат программалары, белгечләр әзерләү программалары буенча белем алучы укучыларга кагыла дип билгеләргә.

3. Түбәндәгеләрнең үз көчен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга,

ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2014 ел, 1 октябрь, 705 нче карарын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2014 ел, 1 октябрь, 705 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 13 февраль, 89 нчы карарын.

4. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\738.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 3 октябрь, 738 нче
карары белән расланды

2016 елга дәүләт һөнәр белеме бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр исеме | Түбәндәге программалар буенча белем алучыларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре, сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү | урта гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр (хезмәт-кәрләр) әзерләү | урта звено белгечләрен әзерләү | бакалавр, белгечләр, магистрлар әзерләү |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга бер тапкыр бирелә торган пособие | 661 | 661 | 661 | 661 |
| 2. | Белем бирү оешмасын тәмамлап чыкканда ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан | 59337 | 59337 | 59337 | 59337 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие | | | | |
| 3. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга уку әдәбияты һәм язу өчен кирәк-яраклар сатып алуга еллык пособие | 2366 | 2366 | 2366 | 6124 |
| 4. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен еллык пособие | 25289 | 25289 | 25289 | 25289 |
| 5. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга, инвалидларга белем алучылар өчен 2016 елның 1 сентябренә кадәр билгеләнгән стипендия күләменнән артмаган күләмдә айлык стипендия | 762 | 762 | 762 | 762 |
| 6. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар | 816 | 816 | 816 | 816 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, инвалид балаларга, инвалидларга белем алучылар өчен 2016 елның 1 сентябреннән билгеләнгән стипендия күләменнән артмаган күләмдә айлык стипендия | | | | |
| 7. | Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга туклану өчен айлык пособие | 5809 | 6695 | 6695 | 6695 |

F:\KARAR\2015\738-1.docx